# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегенең Кулабердино торак пунктында**

**24 ноябрь, 2023 ел** **№ 4**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 24 ноябрендә 11 сәгатьтә 00 минутта булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән «Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?" соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде :

*а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:*

- материаллар сатып алып, урамнарны яктыртуны ремонтлау;

йорт номерлары һәм урам исемнәре белән күрсәткечләрне торак йортларның адрес хуҗалыклары норматив хәлгә китерү.

*б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*

- материаллар сатып алып, су күтәрү манараларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү;
- материаллар сатып алып суүткәргеч челтәрләрен карап тоту;

в*) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

авыл җирлеге торак пункты территориясен карап тоту.

г*) беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:*

- Янгын сүндерү машинасын, җиһазларны, биналарны һәм ДЕПО хезмәткәрен тоту.»

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 29 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 18, бу 62 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 18 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегенең Кулабердино торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлеге Кулабердино авылы территориясендә яшәү урыны һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме

*а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:*

- материаллар сатып алып, урамнарны яктыртуны ремонтлау;

йорт номерлары һәм урам исемнәре белән күрсәткечләрне торак йортларның адрес хуҗалыклары норматив хәлгә китерү.

*б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*

- материаллар сатып алып, су күтәрү манараларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү;

- материаллар сатып алып суүткәргеч челтәрләрен карап тоту;

в*) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

авыл җирлеге торак пункты территориясен карап тоту.

г*) беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:*

- Янгын сүндерү машинасын, җиһазларны, биналарны һәм ДЕПО хезмәткәрен тоту.»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Багай авыл җирлеге Башлыгы Кузнецова Р.Ф.Кузнецова